Соңгы сүз туры килгән бала, «Миндә!» дип, тупны югары күтүрү һәм аны балаларның аякларына ыргыта. Аягына туп тигән бала уеннан чыга. 3–5 бала «тотылгач», уен тәмам була.
Кабатлап уйнаганда, тупны икенче юнәлештә җибәрәләр.

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре Муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе “4нче номерлы “Ләйсән” гомумүсеш төрендәге балалар бакчасы”

***Уйный***

***Үсәбез***

***Уйный***







**Тизрәк урыныңа бар**

Уен балаларны урында ориентлашырга, ритм хисен тоярга, тигез хәрәкәтләр ясарга өйрәтә.

Тәрбияче балаларны колоннага тезә, аннан соң алга басып, үзе балалар белән бергә атлап йөри башлый. Балалар тигез атлап йөрсеннәр өчен, ул башта кул чаба һәм шул ук вакытта:

«Бер-ике, бер-ике, бергә!» – дип әйтә, аннан соң, балаларныә атлавына туры китереп, аларга таныш булган нинди дә булса бер җыр җырлый башлый. Җырның бер куплетын яки бөтенесен җырлап бетергәч, тәрбияче кисәктән генә: «Тизрәк урыныңа бар!» – дип кычкыра, һәм балалар барысы да урыннарына йөгерәләр. Тәрбияче башкалардан алда йөгерүче балаларны үз урынына билгеләп куя.

**Куяннар**

Балалар – «куяннар» – «тау итәгенә» җыелганнар (тау итәге урынына мәйданчыктагы тауны яки башка берәр биеклекне файдаланырга мөмкин). Тәрбияче: «Җылыну өчен куяннар тәпиләрен селкиләр», – диюгә, балалар сикергәлиләр һәм тәпиләрен бер-берсенә бәрәләр. Бераз вакыттан тәрбияче әйтә:

Һава салкын, тын гына,
Басып тору туђдыра,
Җылыныр өчен тизрәк,
Сикерик күңеллеәк.

Шул сүзләрне ишетүгә, балалар тау итәгеннән йөгереп чыгалар һәм кулларын баш өстенә куеп, ике аяклап сикергәлиләр. Җылынып җиткәч, тәрбиячнеәә хәбәр бирүе буенча, яңадан тау итәгенә кайталар. Теләгән балалар белән уен кабатлана.

**Куышу**

Уен мәйданчыгыныә каршы якларына ике туры сызыла. Болар – балаларныђ «өйләре». Барлык балалар бер туры сызыкның артына (өй эченә) басалар. Турылар арасында уйнаучыларның берсе басып тора. Өй эчендә торучы балалар түбәндәге сүзлүрне әйтәләр:

Без, балалар, яратабыз
Йөгереп, сикереп уйнарга.
Әйдә, безне куып кара,
Көчең җитсә тотарга,
Тот!

Тђрбияченең «Бер, ике, өч, инде монда күч!» дигән сүзеннән соң барысы да, өйдән чыгып, каршыдагы өйгә йөгерәләр. Ике өй арасындагы бала йөгерүче балаларны тота. 2–3 бала тотылганнан соң, икенче тотучы сайлана, һәм уен яңадан башлана.

**Туп белән куышу**

Балалар түгәрәк ясап басалар. Түбәндәге сүзләрне әйтә-әйтә, тупны түгәрәк буенча җибәрәләр (бер-берсенә бирәләр):

Бер, ике, өч,
Дүрт, биш, алты,
Туп кемдә калды?
– Миндә!